РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_12_» __ноябрь_ 2024 ел №_271__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карарына (район Советының 2022 елның 27 гыйнварындагы 90 номерлы, 2023 елның 24 июлендәге 191 номерлы, 2023 елның 12 декабрендәге 215 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Яңа редакциядә бәян итәргә:

- «4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа аны 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми» пункты.

- «4.9.4 Урынга барып тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.» пункты.

1.2. Түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә: «4.9.5. Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, ачыкланган хокук бозуларны әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 пунктчасында каралган тәртиптә контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында мондый мөмкинлек күрсәтелгән очракта бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов